ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_10.01.2023__ Мөслим авылы № _5__

**«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 11 ноябрендәге 516 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 11 ноябрендәге 516 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган мөрәҗәгатьне формат-логик яктан тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гариза бирүче электрон формадагы мөрәҗәгатьнең һәр юлын тутырган вакытта автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы мөрәҗәгатьтә тиешенчә тутырылмаган юл ачыкланганда, ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гариза бирүчегә мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмати хәбәр ярдәмендә хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**